ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«16» 03 2019 г.

**КАРАР**

№ 69

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үзгәргән законнар нигезендә муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү мониторингын үткәрү турындагы Нигезләмәне раслау хакында**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлеген камилләштерү максатыннан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән (чыгарылган) муниципаль норматив хокукый актларның үзгәрешләр кергән законнар нигезендә мониторинг үткәрү өчен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына таянып, **Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы карар бирә:**

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үзгәргән законнар нигезендә муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү мониторингын үткәрү турындагы Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2.Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенә Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үзгәргән законнар нигезендә муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү һәм мониторинг үткәрү буенча җаваплы итеп Балтач районы башкарма комитетының юридик бүлеге хезмәткәрләрен билгеләргә һәм юридик бүлек хезмәткәрләренең вазыйфаи күрсәтмәләренә тиешле үзгәрешләр кертергә тәкъдим итәргә.

3.Балтач районы башкарма комитетының юридик бүлегенә әлеге карарның 1 пункты белән расланган Нигезләмәгә таянып эш итәргә тәкъдим итәргә.

4.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына муниципаль норматив хокукый актларның үзгәргән законнар нигезендә, муниципаль берәмлекләр уставларына туры килүен системалы контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максатларында

мониторинг үткәрүне тәэмин итә торган муниципаль норматив хокукый актлар кабул итәргә тәкъдим итәргә.

5.Балтач район башкарма комитетының юридик бүлегенә Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үзгәргән законнар нигезендә муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр һәм мониторинг үткәргәндә методик һәм консультатив ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарны районның baltasi.tatarstan.ru. рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасары һәм Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән ун көн узгач үз көченә керә.

Балтач муниципаль
район башлыгы Р.Р.Нотфуллин